ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
СЕЛО-УБЕЙСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ ДРОЖЖАНОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Улица Мира, дом 40,
Село Новый Убей, Дрожжановский район 422464

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧҮПРӘЛЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ҮБИ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Тынычлык урамы, 40 нче йорт,
Яңа Уби авылы, Чүпрәле районы 422464

Тел.: (84375) 3-55-35, 3-55-36, e-mail: Subey.Drz@tatar.ru,
www. subey -drogganoe.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

18 ноябрь 2021 ел №24

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Уби авыл җирлегендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Уби авыл җирлеге Уставының 12.1статьясы, Уби авыл җирлеге Советының 15.10.2019 ел, № 60/1 карары (14.11.2019 ел, № 64/2 редакциясендә) белән расланган «Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Уби авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе» нигезендә КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Уби авыл җирлегенең Уби торак пунктында гражданнар җыенын 2021 елның 3 декабренә 13.30 сәгатьтә Татарстан Республикасы, Чүпрәле районы, Уби авылы, Кызыл мәйдан урамы, 48 йорт адресы буенча гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча билгеләргә, Үби урта мәктәбе.

2. Гражданнар җыенында түбәндәге мәсьәләне расларга:

"2022 елда Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Уби авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән 500 сум күләмендә үзара салым кертергә һәм алынган акчаларны җирле

әһәмияткә ия түбәндәге эшләрне башкару буенча мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерүгә килешәсезме:

- Үби авылы Тал-Морза авылы буенча гамәлдәге юлга вак таш салу.

«ӘЙЕ» «ЮК»».

3. Әлеге карар рәсми бастырып чыгарылырга (халыкка җиткерелергә) тиеш.

Башкарма комитет җитәкчесе
вазыйфаларын башкаручы Үби авыл
җирлеге Чүпрәле муниципаль
районы Татарстан Республикасы
Чүпрәле муниципаль районы А.П. Ярухин